**Кукмара муниципаль районы**
**Күкшел авылҗирлеге башкарма комитеты**

**Карар**

**2021 елның 17 мае** **№11**

**Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау үткәрү Тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль Законның 14 статьясы һәм «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Кукмара районы прокурорының 2021 елның 16 мартындагы 02-08-02-2021 номерлы тәкъдимен карап, һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауны уздыруның бердәмтәртибенбилгеләүмаксатларында, Күкшел авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау үткәрү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә

4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Күкшел авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе: Хәмидуллин Р.Р.

ОГРН 1021607753298
ИНН 1623002022

Кушымта Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл жирлеге башкарма комитетының 17.05.2021 ел. 11 номерлы карары белән расланды

**Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл Советына, Башлыгына һәм башкарма комитетына (алга таба – җирле үзидарә органнары) кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Гражданнарның җирле үзидарә органнарына кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләренә йогынты ясаучы сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын арттыру максатларында уздырыла.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау елга 1 тапкыр гамәлгә ашырыла.

4. Гражданнарның җирле үзидарә органнарына кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан хисап чорында җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау турында отчет (алга таба – Отчет) рәсмиләштерелә.

5. Отчетта түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- кергән, кабат адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ формасындагы мөрәҗәгатьләрнең саны турында мәгълүмат;
- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;
- шәхси кабул итү вакытында кабул ителгән гражданнарның саны турында;
- гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итү турында;
- мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турындагы (булган очракта) мәгълүмат.

6. Җирле үзидарә органнарына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, тиешле чорда килгән мөрәҗәгатьләрнеисәпкәалып, Күкшел авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла, шул исәптән: Интернет-кабул итү бүлмәсенә яисә электрон почта аша җибәрелгән, гражданнарны шәхси кабул итү барышында, «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәлгән «Кайнар линия» телефоны буенча язма рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә.

7. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау нәтиҗәләре буенча, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр вазыйфаи зат аналитик белешмә төзи.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә аналитик белешмә, шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырыла.